ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17 йорт,Актаныш ав.,423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

______________　　　　　　　　　　__________

**«2023 елга «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге балаларына өстәмә белем бирү оешмаларының туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф оешмаларының һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында»**

«Мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы «Татарстан Республикасы балаларга өстәмә белем бирүнең туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлешле һәм күп профильле мәгариф учреждениеләрендә балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакындагы карары, Актаныш муниципаль районы Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2023 елга Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлештәге һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күп профильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга кушып бирелә торган норматив чыгымнарны расларга. Балаларга өстәмә белем бирү буенча туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлештәге һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күп профильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга 0,65 күләмендә норматив чыгымнарга төзәтмәләр коэффициенты.

2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының финанс-бюджет палатасына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

- әлеге карарның 1 пунктында расланган, балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны;

- әлеге карарның 1 пунктында расланган, балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары гамәлдә булу чоры дәвамында, хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карау.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Л.Р. Сираевага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы Р.А.Ильясов

Расланды
Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән
«___» _______ 20__ №___

**Туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлештәге һәм «Актаныш муниципаль районы»муниципаль берәмлеге балаларга өстәмә белем бирүнең күп профильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар**

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль дислокация | 1 укучыга елына норматив чыгымнар, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетик | авыл җирлеге | 8 251 | 15 280 | 18 336 |
| Физкультура-спорт | авыл җирлеге | 8 150 | 15 093 | 18 111 |
| Техник иҗат | авыл җирлеге | 8 555 | 15 842 | 19 011 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Экологик-биологик | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Хәрби-патриотик | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Социаль-педагогик | авыл җирлеге | 7 948 | 14 718 | 17 661 |
| Социаль-икътисади | авыл җирлеге | 7 948 | 14 718 | 17 661 |
| Табигый фәнни | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |